ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыруның актуаль мәсьәләләре хакында

«Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыруның актуаль мәсьәләләре хакында Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе рәисе Л.Р. Фазлыеваның һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты рәисе А.А. Чубаровның мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыруның актуаль мәсьәләләре хакында мәгълүматны игътибарга алырга.

2. «Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» 2011 елның 20 маендагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының актуальлеген, хокук кулланучылар тарафыннан төрле мәгънәдә аңлашыла торган каршылыклар һәм нормалар булмавын билгеләп үтәргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетына «Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» 2011 елның 20 маендагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыруны тикшереп тору эшен дәвам итәргә.

4. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясенә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

4.1. Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнарының һәм учреждениеләренең социаль

куркыныч хәлдәге балигъ булмаганнар һәм гаиләләр белән эшләүнең заманча технологияләрен кертү эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итәргә.

4.2. Карала торган өлкәдә законнарны камилләштерү белән бәйле мәсьәләләрне законнар белән өстәмә җайга салу таләп ителсә, тиешле тәкъдимнәрне әзерләргә һәм аларны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетына кертергә.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны финанслауны арттыру турындагы мәсьәләне карауны тәкъдим итәргә.

6. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына балигъ булмаганнарда хокукый әдәпне һәм законнарны үтәү ихтыяҗын булдыруга юнәлдерелгән республика чараларын үткәрүне тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

7. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына социаль куркыныч хәлдәге балигъ булмаганнарны мәдәни-ял эшчәнлеге белән кызыксындыруны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

8. Татарстан Республикасының муниципаль районнары, шәһәр округлары башлыкларына балигъ булмаганнар җинаятьчелеген һәм хокук бозуларын профилактикалау өлкәсендә вәкаләтләр башкаруны дәвам итүне тәкъдим итәргә.

9. «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгына Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләр эшчәнлеге турындагы материалларны массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштыруга аерым игътибар бирүне тәкъдим итәргә.

10. Әлеге карарның 4 – 9 пунктларын үтәү барышы турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетына 2027 елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча җибәрергә.

11. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ю.З. Камалтыновка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2026 елның 12 марты
№ 153-VII ДСП